КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 июль г.Казань № 797

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе мәсьәләләре» 2007 ел, 7 ноябрь, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе мәсьәләләре» 2007 ел, 7 ноябрь, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 9 июнь, 453 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 май, 379 нчы; 2011 ел, 9 август, 645 нче; 2012 ел, 29 ноябрь, 1045 нче; 2013 ел, 12 март, 158 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 812 нче; 2014 ел, 26 ноябрь, 918 нче; 2015 ел, 23 июнь, 457 нче; 2015 ел, 21 октябрь, 790 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 423 нче; 2016 ел, 13 август, 558 нче; 2017 ел, 1 март, 123 нче; 2017 ел, 5 август, 556 нчы; 2017 ел, 15 август, 571 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 742 нче; 2018 ел, 26 апрель, 286 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1296 нчы; 2020 ел, 21 август, 719 нчы; 2021 ел, 5 февраль, 59 нчы; 2021 ел, 13 декабрь, 1226 нчы; 2022 ел, 6 октябрь, 1078 нче; 2023 ел, 13 гыйнвар, 5 нче; 2023 ел, 24 март, 346 нчы; 2023 ел, 22 июнь, 739 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацында «2023 елның 1 июленнән» сүзләрен «2024 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктта «(ведомство)» сүзен төшереп калдырырга;

3 бүлектәге астөшермәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин